ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
САЛАУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САЛАГЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.02.2023 Салагыш авылы № 6

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлегендә нотариаль гамәлләр башкару буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының 28.10.2019 № 27 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлегендә нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

- 1 пунктта түбәндәге эчтәлекле 1.13 пунктча өстәргә:

«1.13. нотариаль таныкланган килешүләрнең эчтәлеген чагылдыра торган документларның дубликатларын тапшырырга.».

2. Әлеге карарны веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: https://agryz.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салауш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка чыгарырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 11 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе М.М.Мөхәммәдиев